ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 411-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 411-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2023 елның 23 марты
№ 1909-VI ДС

проект

Татарстан
Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**«Балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

**1 статья**

«Балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре турында» 2009 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), 2015, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2020, № 4 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлешнең 14 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14) «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә башка нигезләр буенча профилактик исәптә торучыларга»;

2) 11 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Җәмәгать тәрбиячесе эше түбәндәге очракларда туктатыла:

1) балигъ булмаган зат 18 яшькә җиткәч;

2) аны башка җәмәгать тәрбиячесе белән алыштырганда;

3) балигъ булмаган зат башка яшәү урынына күчеп киткәндә;

4) балигъ булмаган зат профилактик исәптән төшерелгәндә;

5) җәмәгать тәрбиячесенең, балигъ булмаганның яисә аның ата-анасының (аларны алыштыручы затларның) шәхси үтенече буенча;

6) әлеге Законда каралмаган башка очракларда балигъ булмаганнар эшләре комиссиясе карары буенча.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектына**

**АҢЛАТМА**

«Балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проекты (алга таба - закон проекты) федераль законнардагы үзгәрешләргә туры китерү һәм Татарстан Республикасында балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре институтын камилләштерү максатларында эшләнгән.

«Балигъ булмаганнарның караучысызлыгын һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында», «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 22 һәм 66 статьялары һәм РСФСР белән Россия Федерациясенең аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2018 елның 27 июнендәге 170-ФЗ номерлы Федераль закон белән балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссияләр турындагы РСФСР Югары Советы Президиумының 1967 елның 3 июнендәге Указы белән расланган, балигъ булмаганнарны балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссиядә исәпкә кую каралган нигезләмә үз көчен югалткан дип танылды.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссияләр турында якынча нигезләмәне раслау хакында» 2013 елның 6 ноябрендәге 995 номерлы карары һәм «Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссияләр турында» 2011 елның 20 маендагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән балигъ булмаганнарны балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясендә исәпкә кую да каралмый.

Федераль һәм республика законнарына туры килүне тәэмин итү максатларында «Балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре турында» 2009 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законыннан балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссиядә исәпкә алуга кагылышлы нигезләмәләрне төшереп калдырырга кирәк.

Күрсәтелгәннән тыш, җәмәгать тәрбиячесе беркетелергә мөмкин булган балигъ булмаганнар категорияләре исемлегендә «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясында каралган профилактик йогынты формаларының берсе булган башка нигезләр буенча профилактик исәптә торучы балигъ булмаганнар категориясен беркетергә тәкъдим ителә.

Җәмәгать тәрбиячеләрен әлеге категориягә беркетү ата-аналарга (башка законлы вәкилләргә), беренче чиратта, белем бирү учреждениеләренә сәбәпсез йөрмәгән балигъ булмаганнарны тәрбияләүдә, аларның белем бирү оешмаларында, җәмгыятьтә һәм көнкүрештә үз-үзләрен тоту кагыйдәләрен үтәүдә ярдәм күрсәтү өчен кирәк. Балигъ булмаганнарның билгеләнгән категориясен кертү профилактик

исәптә торучы балигъ булмаганнарга индивидуаль якын килү ихтыяҗы белән бәйле. Индивидуаль профилактик эш алып бару максатыннан балигъ булмаганнарның караучысызлыгын һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнары һәм учреждениеләре исәп-хисап алып бара.

Бәян ителгәннәрне исәпкә алып, закон проектында «Балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 1 өлешенең 14 пунктын һәм 11 өлешенең 4 пунктын яңа редакциядә бәян итү күздә тотыла. 3 статьяның 11 өлешендәге башка үзгәрешләр техник характерда һәм формулировкаларны төгәлләштерүгә һәм аларның үзара килешүчәнлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән.

Үзгәрешләр профилактика эшенең башлангыч стадиясендә балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре институтының төп бурычларын эчке эшләр органнары белән, шулай ук балигъ булмаганнарның җәмгыятькә каршы гамәлләрен кисәтү, хокук бозулар һәм җинаятьләр кылу, спиртлы эчемлекләр, наркотик һәм психотроп матдәләр куллануны кисәтү максатыннан балигъ булмаганнарның караучысызлыгын һәм хокук бозуларын профилактикалау системасын тәшкил итүче башка органнар һәм учреждениеләр белән үзара хезмәттәшлектә тормышка ашырырга мөмкинлек бирәчәк.

**«Балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

**«Балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы закон проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.